Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы

**КАРАР**

«02» октябрь 2017 ел № 64

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 17 номерлы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты карары, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 63 номерлы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. 2017 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

1)«2018 елда үзара салым кертү өчен 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 1000 (мең) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү белән килешәсезме:

1. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Түбән Бәрәскә, Олы Бәрәзә, Олы Өшкәтә авыллары территориясен чистарту;
- Түбән Бәрәскә авылында урам яктыртучы челтәрләрне ремонтлау;
- Олы Бәрәзә авылында чишмәләрне һәм коеларны төзекләндерү.

2. Авыл җирлеге территориясендә җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- төзелеш материаллары сатып алу, Түбән Бәрәскә, Олы Бәрәзә, Олы Өшкәтә авыллары урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү.

3. Түбән Бәрәскә авылындагы паркны төзекләндерү:
- бетон юллар салу;
- эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру;
- балалар, уен һәм спорт җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру;
- беседка урнаштыру;
- чәчәклекләр һәм газон урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК»

2) «2017 ел референдумы буенча алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Олы Бәрәзә, Түбән Бәрәскә, Олы Өшкәтә авыллары урам юлларын ремонтларга һәм төзекләндерергә сез ризамы?

ӘЙЕ ЮК»

3. Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең сайлау комиссияләренә, гамәлдәге законнар нигезендә, «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

4. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономияләү очрагында, әлеге акчалар планлаштырылган эшләрне башкару өчен акча җитәрлек булмаган юнәлешләрне финанслауга юнәлтелә.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру, «Этнә таны» район газетасында бастырып чыгару һәм http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтка урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Фатыхова А.В.